| | |
|---|---|
| БАВЛИНСКИЙ<br>ГОРОДСКОЙ СОВЕТ<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БАУЛЫ ШӘҺӘРЕ<br>СОВЕТЫ |

РЕШЕНИЕ КАРАР

14.08.2023 Баулы № 104

Татарстан Республикасы Баулы шәһәр Советының 2017 елның 25 октябрендәге 60 номерлы “Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы “Баулы шәһәре” муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү, чисталыкны һәм тәртипне саклау кагыйдәләрен раслау турында” карарына өстәмәләр кертү турында

“Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында” Федераль законга үзгәрешләр кертү һәм “Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында” Федераль законның 7 статьясындагы 6 өлешендәге 16 пунктының үз көчен югалтуын тану хакында "” 2019 елның 18 июлендәге 184-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Баулы шәһәр Советы КАРАР ИТТЕ:

1. “Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы “Баулы шәһәре” муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү, чисталыкны һәм тәртипне саклау кагыйдәләрен раслау турында” 2017 елның 25 октябрендәге 60 номерлы Баулы шәһәр Советы карарына (2020 елның 29 маендагы 131 номерлы, 2021 елның 18 февралендәге 23 номерлы, 2022 елның 11 апрелендәге 58 номерлы, 2022 елның 1 декабрендәге 76 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге өстәмә кертергә:

4 -нче бүлекнең 4.16. пунктының з) пунктчасын түбәндәге эчтәлектә тулыландырырга:

«з) барлык гомуми файдаланудагы парковкаларда, шул исәптән социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктурасы объектлары (торак, иҗтимагый һәм җитештерү биналары, корылмалар, шул исәптән физкультура-спорт оешмалары, мәдәният оешмалары һәм башка оешмалар урнашкан урыннар), ял итү урыннары тирәсендә, I, II төркем инвалидлар идарә итә торган транспорт чараларын һәм мондый инвалидларны һәм (яки) инвалид балаларны йөртүче транспорт чараларын бушлай парковкалау өчен 10 проценттан да ким булмаган, урыннар (әмма бер урыннан да ким булмаган урыннар) бүлеп бирелә. Күрсәтелгән транспорт чараларында «Инвалид» билгесе урнаштырылырга һәм әлеге транспорт чаралары турында мәгълүмат федераль инвалидлар реестрына кертелергә тиеш.».

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы сайтында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Баулы шәһәр Советының экологик куркынычсызлык, табигый ресурслар һәм халыкның тормыш-көнкүрешен тәэмин итү мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Баулы шәһәре Мэры,
Шәһәр Советы рәисе И.И. Гозәеров